## **31.03.2021 ел.** Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре


**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәисе урынбасары Марат Готыф улы Әхмәтов бездә кунакта**

Буген безнең гимназиядә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәисе урынбасары **Марат Готыф улы Әхмәтов** башлыгында ***"Хәзерге чор шартларында рухи тормышыбызның усешен тәэмин итү: милли матбугат чаралары һәм татар телендә белем, тәрбия бирү мәсьәләләре"*** дип аталган түгәрәк өстәл узды.








Переключатель
АКБ








ТАНЫЛМЫЙДЫР КЕШЕ ГӘРЧӘ ТЫШЫННАН,

Апрель • 2021 ел • № 4 (40)
minem-gimnaziyam.jimdo.com

# Минем гимназиям

2 нче ГИМНАЗИЯ

«М. Вахитов исемендәге 2 нче гимназия» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе газетасы

### Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү комиссиясе рәисе

# Марат Әхмәтов гимназиядә!

Чаллыга Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов килде. ТР Дәүләт советы депутатлары – Айрат Зарипов, Камил Нугаев, Марсель Мингалимов, «Татмедиа» АҖ генераль директоры Шамил Садыйков, ТР Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, язучы Марсель Галиев, шагыйрә Шәмсия Җиһангирова белән берлектә ул безнең татар гимназия эшчәнлеге белән танышты. Гимназиядә яңа уку елына гына капиталь ремонт тәмамланды, бөтен җиһазлар яңартылды. Сыйныфлар белән танышып, укучылар, укытучылар белән аралашканнан соң Марат Әхмәтов: «Менә бу – Чаллыда тулыканлы милли тормыш, мәгариф үрнәге. Эчтәлек көчле. Мондый мәктәпләр үрнәгендә балаларда телебезгә, халкыбызга мәхәббәт тәрбияләп булыр», – диде.

Тулырак: http://shahrichalli.ru/news/kich-bgen-irtg/challyda-marat-khmtov

